ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.64, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БОРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет ур., 62 нче йорт, Татар Борнашы авылы,
422579


ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

29.01.2024 — 3

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48,

с. Татарское Бурнашево

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлегендә җирләү хезмәтләре күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 декабрендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы һәм 15.06.2010 ел № 468 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авылы җирлегендә 1 февральдән мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 8370,20 сум күләмендә расларга һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районының
Борнаш авыл җирлеге башлыгы — С.В.Бурукин

Югары Ослан муниципаль
районы Борнаш авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 2024 елның
29 гыйнварындагы 3
номерлы карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районында 2024нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3183,60 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1360,74 |
| 4. Зиратта җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3825,86 |
| Барлыгы | 8370,20 |